Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы карары

26.09.2017ел. № 66

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 24.03.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Башкарма комитетының «җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 25.09.2017 № 6 карары, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 26.09.2017 № 65 карары, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы карары нигезендә:

1. 2017 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раслау:

"2018 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы:

Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызуны оештыру:

- «Биби Төбәк» чишмәсеннән резервуарга кадәр суүткәргечне алыштыру, арасы 1 км.

Җирлек чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау: Олы Яңасала, Шәпкә авыллары; - Комсомол урамында җиңел машиналар өчен күпер төзү.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: - Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк урамы, 1, Шәпкә авылы, Клубная урамы, 14, шулай ук «Идел таңнары» газетасында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Яңасала авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы Яңасала авыл җирлеге Советы Рәисе
муниципаль район башлыгы И. Х. Шиһабеев